| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

___20.04.2015___ г. Казань № __4955/15___

**«Педагог – мастер» мастер-классларның өстәмә авторлык программалары республика күләмендәге конкурс турында**

Мәгарифне үстерүнең актуаль мәсьәләләрен нәтиҗәле, инновацион юллар белән хәл итүгә юнәлдерелгән мастер-классларның өстәмә программалары авторлары – иҗади эшләүче педагогларны (укытучыларны һәм тәрбиячеләрне) ачыклау, шулай ук, Татарстан Республикасында укытучыларның, тәрбиячеләрнең заманча «Педагог – мастер» референт төркемен формалашыру максатыннан чыгып, боерам:

1. 2015 нче елның 27 апреленнән 1 нче июленә кадәр республика күләм «Педагог – мастер» мастер-класларының өстәмә авторлык программалары конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрергә.

2. Кушымталарны (конкурс турындагы 1 нче кушымтада бирелгән нигезләмә, конкурсның 2 нче кушымтада бирелгән оештыру комитеты составы) расларга.

3. Конкурсның операторы итеп «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә профессиональ белем бирү дәүләт автоном белем бирү учреждениесен (Хәмитов Р.Г.) (алга таба – Мәгарифне үстерү институты) билгеләргә.

4. Өстәмә һөнәри белем бирү бүлегенә (Шәяхмәтова Р.И.) конкурсны үткәрүне контрольгә алуны йөкләргә.

5. Татарстан Республикасы муниципаль берләшмәләрнең башкарма комитеты мәгариф бүлекләре (идарәләре) житәкчеләренә Конкурста муниципаль районнарда эшләүче укытучылар, тәрбиячеләр, педагогларның актив катнашуын тәэмин итәргә.

6. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары А.И.Поминовка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры**
**урынбасары – министр** **Э.Н. Фәттахов**

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән Министрлыгының 2015 елның 20 апрелендәге № 4955/15 лы боерыгына 2 нче кушымта

**Мастер-класс өстәмә авторлык программаларының «Педагог-мастер» республика күләмендәге конкурс**
**НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

## 1. Гомуми нигезләмә

1.1. Әлеге Положение Татарстан Республикасы гомуми белем бирү һәм дәүләт һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре (укытучы һәм тәрбияче) арасында уздырылучы мастер-класс «Педагог-мастер» өстәмә авторлык программаларының республикакүләм конкурсының (алга таба – конкурс) максат, бурыч, үткәрү шартларын һәм оештыру тәртибен билгели.

1.2. Мастер-класс формалашкан актуаль педагогик тәҗрибәне (конкрет методик алымнар яки ысулларны, укыту методикасын, укыту һәм тәрбия технологияләрен) таратуның (трансляцияләүнең) заманча интерактив формасы булып тора. Аның нәтиҗәсе булып, мәгариф хезмәткәрләренең профессиональлек дәрәҗәләрен күтәрү, аларны инновацион педагогик тәҗрибәгә тарту тора.

1.3. Конкурсның максаты булып, иҗади эшли торган укытучыларны, тәрбиячеләрне – мәгарифне үстерүнең актуаль мәсьәләләрен нәтиҗәле, инновацион юллар белән хәл итүгә юнәлдерелгән мастер-классларның өстәмә программалары авторлары булып торган иҗади эшләүче педагогларны ачыклау тора.

1.4. Конкурсның максатлары:

– Татарстан Республикасында инновацион юллар белән хәл итүгә юнәлдерелгән, аларны чагылдырырга сәләтле укытучыларның, тәрбиячеләрнең заманча “Педагог – мастер”лардан торган референт төркемен формалашыру;

– иң яхшы авторлык педагогик практика һәм иҗади лабораторияләрнең республика күләмендәге банкын формалаштыру;

– нәтиҗәле педагогик тәҗрибәне диссеминацияләү;

– педагогларның профессиональ үсешен стимуллаштыру;

– мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрүдә гамәли юнәлешне көчәйтү;

– педагогларның профессиональ үсеше халәте һәм тенденцияләренә мониторинг үткәрү.

1.5. Конкурста Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү һәм гомуми белем бирү оешмаларында эшләүче берләшмәләрдә эшләүче педагоглар (укытучылар һәм тәрбиячеләр) катнаша.

1.6. Конкурсның оештыручысы булып Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы, операторы булып "Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты" өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном белем бирү учреждениесе (алга таба – "Татарстан Республикасы мәгарифне үстерү институты") тора.

1.7. Конкурс Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән расланган оештыру комитеты тарафыннан башкарыла.

1.8. Мастер-классларның өстәмә авторлык программаларына һөнәри-җәмгыяви экспертиза Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 12.11.2014 елда чыккан "Татарстан Республикасы мәгариф хезмәткәрләренең персонификацияләштерелгән системасы турындагы 6492/14 нче номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен үстерү программаларын (модульләрен) бәяләү буенча республика Эксперт советы (алга таба – эксперт советы) тарафыннан үткәрелә.

1.9. Конкурсның җиңүчеләренә Татарстан Республикасы өстәмә һөнәри белем бирү системасында үткәрелә торган квалификация күтәрү курсларында стажировканың практикасы, проблемалы семинарлар, фәнни-гамәли конференцияләр кысаларында мастер-класслар үткәрү хокукы бирелә.

## 2. Конкурсны үткәрүнең шартлары

2.1. Мастер-классларның программалары предметларны алып баручы укытучылар һәм тәрбиячеләр тарафыннан авторның инновацион тәҗрибәсе, аның методик системасы, шулай ук мәгариф белән идарә итүнең мастер-класслары программаларын үз эченә ала, мәгарифне үстерүнең мөһим мәсьәләләрен, аларны хәл итүнең ысулларын чагылдырган төрле юнәлешләре һәм формалары, белем бирү һәм тәрбиянең методикалары һәм технологияләре буенча төзелә.

2.2. Конкурс 2015 нче елның 27 апреленнән 2015 елның 01 июленә кадәр 2 этапта үткәрелә;

Беренче этап – 2015 нче елның 15 нче июненә кадәр читтән торып үткәрелә. Әлеге этапта конкурсны катнашучылары оештыру комитетына документлар тапшыралар һәм алар өйрәнелә, экспертлар тарафыннан бәяләнә;

Икенче этап – 1 июльгә кадәр турыдан-туры катнашу формасында үткәрелә. Бу этапта конкурсантлар мастер-классларының өстәмә авторлык программаларын яклыйлар, конкурска йомгак ясала.

2.3. Конкурсның башлануы, аны үткәрүнең бөтен шартлары, беренче, икенче этапларының һәм конкурсның гомуми нәтиҗәләре турындагы мәгълүматлар "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәренең Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтында һәм "Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты"ның рәсми сайтында урнаштырыла.

2.4. Конкурста катнашу өчен документлар 2015 елның 27 апреленнән башлап, 2015 елның 1 июленә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420015 г. Казань,

ул. Б. Красная, д.68, ГАОУ ДПО “Институт развития образования Республики Татарстан”

2.5. Конкурста катнашу өчен кирәкле документлар исемлеге:

– конкурста катнашу өчен гариза - анкета (1 нче кушымта);

– мастер-классның программасы ( 2 нче кушымта);

– портфолио (рецензияләр, бәяләмәләр, программаларга эксперт бәяләмәләре (булган очракта).

2.6. Мастер-классларының өстәмә авторлык программаларын яклау, конкурста катнашучылар тарафыннан программаларының проектларының эчтәлеге эксперт советына кыскача шәрехләнә. Моның өчен конкурста катнашучыга 5-7 минут вакыт бирелә, шул вакыт эчендә тәкъдим ителә торган эшнең конкурс максатларына һәм бурычларына туры килүе чагылыш табарга тиеш.

2.7. Конкурста катнашучы түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

– төп эш урыны – Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү һәм гомуми белем бирү оешмасы;

– стажы – педагогик стажы өч елдан да ким булмаска тиеш;

– тәкъдим ителгән программа әлеге положениенең 3.2. пунктында күрсәтелгән критерияләргә туры килергә тиеш;

– мастер-классның программасы проекты уңышлы якланырга тиеш.

## 3. Мастер-классларының өстәмә авторлык программаларын карау һәм конкурска сайлап алу тәртибе

3.1. Оештыру комитеты тарафыннан

– мастер-классларының өстәмә авторлык программаларын кабул итеп алу оештырыла;

– программа проектлары авторлары белән хезмәттәшлек итү тормышка ашырыла.

3.2. Конкурска килгән материалларны кабул итеп алу һәм экспертиза үткәрү программа эчтәлегенең таләпләргә туры килү-килмәвеннән чыгып һәм авторның түбәндәге критерийлар буенча мастер-класс үткәрүгә әзерлекләреннән чыгып билгеләнә:

– мастер-класска сайлап алынган теманың (проблеманың) әһәмиятлелеге (сәгатьләр саны);

– материал эчтәлегенең яңалык (инновация) дәрәҗәсе;

– материалның эшләнү дәрәҗәсе;

– мастер-классның фәнни-методик тәэмин ителеше, шул исәптән, тыңлаучылар өчен методик киңәшләр, таратма материалларның булуы;

– авторның коммуникатив компетенциясе һәм аның мастер-класс үткәрүгә әзерлеге.

3.3. Конкурста карала торган эшләргә экспертиза экспертлар советы тарафыннан әлеге положениенең 3.2. пунктында чагылдырылган конкурска сайлап алу критерияләре нигезендә баллар куелу юлы белән башкарыла.

3.4. Баллар һәр критерий буенча 5 баллы шкала нигезендә (0 дән 5 кә кадәр) эксперт советы тарафыннан билгеләнә һәм һәр проект буенча әлеге положениенең 3 нче кушымтасы нигезендә эксперт нәтиҗәсе ясала.

3.5. Эксперт советы эшенең нәтиҗәләре экспертлар ясаган нәтиҗәләр теркәлгән беркетмә буларак формалаштырыла.

3.6. Эксперт советы тарафыннан конкурс нәтиҗәләрен чагылдырган беркетмә төзелеп тапшырылганнан соң, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан “Педагог-мастер” конкурсы җиңүчеләре турында боерык чыгарыла, кул куелган моменттан алып, 3 көн эчендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтына элене.

3.7. Конкурста җиңүчеләргә Татарста Республикасы өстәмә һөнәри педагогик белем бирү системасы квалификация күтәрү, стажировка практикалары, проблемалы семинарлар, фәнни-гамәли конференцияләр үткәрү барышында мастер-класслар үткәрә алу хокукы турындагы сертификатлар бирелә.

**4. Эксперт комиссиясенең эше һәм карары белән риза булмау**

4.1. Эксперт советының карарлары, эшчәнлеге Россия Федерациясе законнар җыелмасында каралган тәртиптә кире каралырга мөмкин.

Республика күләмендәге «Педагог-мастер» мастер-класслар өстәмә авторлык программаларының конкурсы нигезләмәсенә
1 нче кушымта

Республика күләмендәге
«Педагог-мастер» конкурсының
оештыру комитетына

Ф.И.О.__________________________________________
Вазифасы_______________________________________
Эш урыны____________________________________

**ЗАЯВКА-АНКЕТА**

«Педагог-мастер» конкурсында катнашу өчен экспертизага минем
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
мастер-класс өстәмә программасын кабул итүегезне үтенәм.
Тыңлаучыларның максатчан төркеме_____________________________________
**Үзем турында хәбәр итәм:**
Туу елым, көнем______________________________________________________
Белемем _____________________________________________________________
Педагогик стажым _______, идарә итү стажым _____________________________
Бүләкләүләр, бүләкләү елы______________________________________________
Гыйльми дәрәҗәнең булуы______________________________________________
Һөнәри конкурсларда катнашу___________________________________________
_____________________________________________________________________
Басма эшләрнең авторы (соавторы) булып торам__________________________
_____________________________________________________________________
Элемтә өчен телефон __________________________________________________
Мастер-класс өстәмә авторлык программаларын экспертизага кабул итү тәртипләре белән таныштым һәм килешәм________________________________________

Имза______________________________
Дата ______________________________

Республика күләмендәге «Педагог-мастер» мастер-класслар өстәмә авторлык программаларының конкурсы нигезләмәсенә
2 нче кушымта

**“Педагог-мастер” мастер-класcларның өстәмә авторлык программаларының структурасы**

**1. Титул бите**

Мастер-классның өстәмә авторлык программасының исеме, тыңлаучыларның максатчан төркемен күрсәтү; автор турында мәгълүмат: ФИО, эш урыны, квалификация.

**2. Аңлатма язуы**

Максатчан төркем өчен мастер-классның өстәмә авторлык программасының актуальлеген һәм нәтиҗәлелеген нигезләү; көтелгән нәтиҗәләр; белем бирү процессында теманы апробацияләү турында мәгълүмат, әйтелгән (кабул ителгән) юнәлеш буенча программаны тормышка ашыруда конкурста катнышучының ресурс һәм һөнәри мөмкинлекләре.

**3. Мастер-класс программасының эчтәлеге**

Программаның эчтәлеге мастер-классның формасы һәм темасыннан чыгып төзелә, мастер-классның төзелешен (структурасын) һәм төп фикерләрен чагылдырырга, үз педагогик тәҗрибәсенең, билгеле бер (конкрет) белем яки тәрбия дәресләренең һәм чараларының, туры килгән методик һәм технологияләрнең эчтәлекле өлешләрен, мастер-класста катнашучыларның диалогта үзара бәйләнеш шартларының тасвирламасын ачарга тиеш.

Республика күләмендәге «Педагог-мастер» мастер-класслар өстәмә авторлык программаларының конкурсы нигезләмәсенә
3 нче кушымта

**Мастер-класс өстәмә авторлык программасына эксперт нәтиҗәсе**

| Критерий | Баллар 0 дән алып 5 кадәр |
|---|---|
| Мастер-класс темасының (проблемасының) актуальлеге, күләме (сәгатьләр саны) | |
| Материал эчтәлегенең яңалыгы (инновационлыгы) дәрәҗәсе | |
| Материалның эшләнү дәрәҗәсе | |
| Мастер-классның фәнни-методик тәэмин ителешенең дәрәҗәсе, шул исәптән тыңлаучылар өчен методик киңәшләр һәм таратма материалның булуы (барлыгы) | |
| Авторның коммуникатив комптенциясе һәм мастер-классны үткәрүгә әзерлеге дәрәҗәсе | |